**РАСЛЫЙМ:**
Казан шәһәре Вахитов районының
«Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 136
нчы катнаш төрдәге балалар бакчасы»
автономияле мәктәпкәчә белем муниципаль
учреждениесе мөдире ________ Г.И.Сибгатова
"31" 08 2022 ел
Приказ №ы 1 көне 31.08.2022
**КАБУЛ ИТЕЛГӘН:**
Педагоглар советында
Протокол №ы 1 көне 31.08.2022

# Казан шәһәре Вахитов районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 136 нчы катнаш төрдәге балалар бакчасы» автономияле мәктәпкәчә белем муниципаль учреждениесендә татар теле тәрбиячесе Тимофеева Раиса Петр кызының

# татар балаларын ана теленә өйрәтү буенча эш программасы

# 2022-2023 нче уку елы



**Эчтәлек**

1. МАКСАТЧАН БҮЛЕК
1.1. Аңлатма язуы
1.2. Программаның максаты һәм бурычлары
1.3. Программаның принциплары
1.4. Балаларның яшь үзенчәлеге
1.5.Үзләштереләсе проектлар, темалар (ана теле)
1.6. Программа буенча белем бирү дәрәҗәсен билгеләү (ана теле)

II ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ
2.1. Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү (биш белем өлкәсендә)
2.2.Эш төрләре һәм формалары
2.3 Комплекслы-тематик планнар (ана теле)
2.4. Балалар белән эш
2.5. Ата- аналар белән эш
2.6. Педагоглар белән эш
2.7. Җәмгыять оешмалары белән бәйләнеш
2.8. Педагогик процессны тулыландыру
2.9. Уз белеменне устеру, квалификация кутэру буенча эш

III ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ
3.1. Материаль - техник тәэмин ителү
3.2. Программалар белән һәм методик яктан тәэмин ителеш
3.3. Тавышлы күрсәтмәлелек
3.4.Күрсәтмә, таратма материал
3.5. Норматив документлар
Файдаланылган әдәбият

## 1. МАКСАТЧАН БҮЛЕК

### 1.1. Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында (28. 07. 2004 N 44-ЗРТ) һәм «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» (25.10.2013 № 794) буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган.

Бу — республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен үз эченә ала. Балалар бакчаларында балаларга рус һәм татар телләрен өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максаты куелган. Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Туган телне саклау һәм үстерү – көнүзәк мәсьәлә. Федераль дәүләт белем бирү стандартларында да дәүләт телләренә зур игътибар бирелә. Шәһәр шартларында үскән балаларның күбесе, гаиләдә ана теленә мөнәсәбәт дөрес булмау сәбәпле (мәсәлән,татар гаиләләрендә русча сөйләшү), үз туган телен икенче тел буларак өйрәнә башларга мәҗбүр. Милли үзаңның нигезе гаиләдә, туган телдә даими сөйләшү аркасында гына салынуын ата-аналар аңлап бетермиләр. Югарыда китерелгән фикерләргә нигезләнеп, без дә туган телен  яхшы белмәгән бала, һичшиксез, балалар бакчаларында ук үз телен өйрәнә башларга яки белгән кадәрлесен камилләштерергә дигән фикерне алга сөрәбез. Безгә, татар балалар бакчасында эшләүче татар теле тәрбиячеләренә, хәзерге көндә бу юнәлештә эшләү зарур. Шуңа күрә без, балаларга ана телен өйрәтүдә Хазратова Ф.В., Зарипова З.М. җитәкчелегендә төзелгән “Туган телдә сөйләшәбез”  методик кулланмаларга нигезләнеп эшләргә карар кылдык. Методик кулланманың беренче бүлегендә шәһәр һәм район үзәкләрендә яшәүче татар балаларының сөйләмен үстерү һәм аларны рус теленә өйрәтү комплекслы-тематик планнар бирелгән. Методик кулланманың икенче бүлегендә рус төркемнәрендә тәрбияләнүче, гаиләләрендә җитәрлек дәрәҗәдә татарча аралашмаган, 2-7 яшьлек татар балаларының сөйләмен үстерү һәм аларны ана теленә өйрәтү комплекслы-тематик, календарь-тематик планнар һәм диагностика сораулары бирелгән.

Методик кулланмаларда һәр үсмер төркемдә атнага өч эшчәнлек исәбеннән төзелгән. 4-7 яшьлек балалар өчен өченче эшчәнлекләр бөтен

төркем белән уздырыла торган итеп кертелгән. Эшчәнлекләрдә балаларда аралашуга теләк уяту,бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычлары куелгәан. Эшчәнлек конспектларында тәрбияче өчен аңлатмалар, әдәбият, җиһазлар, лексик доза, эш төрләре күрсәтелган. Методик кулланмаларда балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. Методик кулланманың икенче бүлегендә план ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Бу темаларның күбесе һәр төркемдә диярлек кабатлана. Шуңа күрә, гадидән катлаулыга бару - кулланмада төп методик **принцип**ларның берсе.Эшчәнлек үрнәкләрендә авторлар боларны мөмкин кадәр эзлекле сакларга тырышкан. Уртанчылар төркемендә алты проект өстәлгән: “Ашамлыклар”, “Татар халык ашлары”, “Халык җәүһәрләре”, “Киемнәр”, “Күчмә кошлар”,”Сабантуй”. Уртанчылар төркеме балаларын –мы, -ме сорау кисәкчәләре белән таныштыру, шулар ярдәмендә өстәмә сорау бирү һәм дөрес җавап кайтару максаты куелды.

5-6 яшьлек балалар эшчәнлеген оештырганда, түбәндәге проектлар өстәлгән: “Абдулла Алиш”, “Мин яратам сине, Татарстан!”, “Кунак булсаң – тыйнак бул”, “Муса Җәлил безнең күңелләрдә”, “Чисталыкта – матурлык”, “Җиңү алып килде безгә май”, “Хәрәкәттә – бәрәкәт”. Бу темалар әдәп-әхлак, патриотик хисләр тәрбияли. Бу яшьтә балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологик сөйләмне камилләштерүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына “Икмәк – яшәү терәге”, “Башкалам – Казан”, “Кышлаучы кошлар”, “Бөтендөнья телләр көне”, “Мәктәп”, “Урман” проектлары кертелгән.

Бу төркемнәрдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог, сәхнәләштерү, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү кебек эш формаларын күздә тота. Эшчәнлекләр матур әдәбият әсәрләрен уку, ятлау, халык аваз иҗатын өйрәнү кебек эш формалары кулланып оештырыла.

Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләре буенча, эшчәнлекләр уен рәвешендә оештырыла. Балалар төрле ситуацияләр чишәләр, уеннар уйныйлар, сәяхәткә баралар, күзәтәләр һәм шул рәвешле телне тоемлау сәләте булдыралар, ана телендә дөрес итеп сөйләшергә өйрәнәләр. Эшчәнлек ахырында балаларга проблемалы сораулар куела һәм алган белемнәрен ныгыту өчен юнәлеш бирелә.

“Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел” методик кулланмасы – балаларыбызга халкыбызның тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә хөрмәт, әти- әниләргә, өлкәннәргә

карата итәгатьлелек тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

### 1.2. Программаның максаты һәм бурычлары

Максат: балалар бакчаларында балаларга туган (ана) телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру.

Бурычлар:

1) балаларны ана телләрендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;

2) тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;

3) бәйләнешле сөйләм үстерү;

4) тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау)сәләте булдыру.

### 1.3. Программа принциплары.

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

*Интеграция һәм дифференциация принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

*Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы*: аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту; Белем бирүне комплекслы-тематик принципка корып оештыру;

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы* - гадидән катлаулыга таба бару. *Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

## 1.4.Балаларның яшь үзенчәлекләре

### Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

Бу яшьтә баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуда мөстәкыйльлеге үсеш ала. Балалар өлкәннәр белән практик эшләрдә (йомыш үтәү, күмәк уеннар) аралашуны дәвам итү өстенә интеллектуаль аралашуга да омтылалар. Бу күпсанлы сораулар (Нигә?, Ни өчен?, Нәрсә өчен?) бирүдә һәм өлкәннәрдән яңа информация алырга теләүдә күренә. Балаларның сүзлегендә теләктәшлек, кеше хәленә керә белү, кызгану сүзләре барлыкка килә. Яшьтәшләрен үзләренә җәлеп итү өчен балалар аралашуның ситуациясенә карап, интонация, ритм, сүз тизлеген җайлыйлар. Өлкәннәр белән аралашу вакытында сөйләм этикеты кагыйдәләрен үтәп, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, юату, кызгану, кеше хәленә керә белү сүзләрен кулланалар. Бу яшьтә баланың сөйләме бәйләнешле һәм эзлекле була.

### Зурлар төркеме (5-6 яшь)

Алтынчы яшьтә баланың сөйләм үсешендә мөхим үзгәрешләр барлыкка килә. Авазларны дөрес әйтү бу яшьтә норма булып тора.Балалар сөйләмдә гомумиләштерүче, күпмәгънәле сүзләр, антонимнар, синонимнар куллана башлыйлар. Аларның сүзлеге профессияне, социаль учреждениеләрне аңлатучы сүзләр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына баетыла. Балалар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнеп, мөстәкыйль рәвештә уенлы һәм эшлекле диалоглар төзергә, туры һәм кыек сөйләмне кулланырга өйрәнәләр, тасвирлау һәм хикәяләү монологында геройның хәлен, кәефен, эпитетлар һәм чагыштырулар кулланып, бирергә сәләтле. Балалар үзара кара – каршы сөйләшергә, үзләренә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм шулай ук тиешле репликаны кулланып җавап бирергә сәләтлеләр. Бу яшьтәге балалар уен ситуацияләре, проблемалы – эзләнүле уен ситуациләрен барлыкка китереп, күрсәтмә әсбаплар, мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)

Бу яшьтә баланың сөйләме төрле контингет кешеләре (өлкәннәр һәм яшьтәшләре, таныш һәм таныш булмаган кешеләр) белән аралашуга мөмкинлек бирә. Балалар авазларны дөрес әйтү генә түгел, фонемаларны һәм сүзләрне таныйлар. Телнең орфологик системасын үзләштерү аларга

исемнәрнең, фигыльләрнең һәм сыйфатларның катлаулы грамматик формаларын төзергә мөмкинлек бирә. Мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр, аудио – видеоязмалар, уку – укыту методик комплектларын кулланып предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне һәм сүзтезмәләрне сөйләмдә, аралашуда актив кулланалар. Гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре белән балаларның лексикасы баей, сүз байлыклары арта.. Бу яшьтәге балалар төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзиләр. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары бик еш сөйләмдә катлаулы җөмләләр кулланалар. 6—7 яшьтә баланың сүз байлыгы арта. Диалог төзегәндә бала сорауларга тулы җавап бирергә, үзе сораулар бирергә, әңгәмәдәшен аңларга тырыша. Монологик сөйләм дә актив рәвештә үсә. Балалар эзлекле һәм бәйләнешле итеп сөйли алалар.

## 1.5. Үзләштереләсе проектлар, темалар (ана теле): Уртанчылар

| | |
|---|---|
| 1. | Без балалар бакчасында |
| 2. | Мин - дөньяның бер кешесе |
| 3. | Ю |
| 4. | Көз |
| 5. | Куян күчтәнәчләре |
| 6. | Көз күчтәнәчләре |
| 7. | Табын янында. |
| 8. | Татар халык ашлары. |
| 9. | Безнең уенчыклар |
| 10. | Кыш |
| 11. | Халык җәүһәрләре |
| 12. | Ватанны саклаучылар. |
| 13. | 8 март |
| 14. | Яз |
| 15. | Күчмә кошлар |
| 16. | Савыт-саба |
| 17. | Апрель җитсә, исемеңне җырына куша тургай |
| 18. | Йорт хайваннары |
| 19. | Минем дусларым |
| 20. | Сабантуй бәйрәме |

## Зурлар

| | |
|---|---|
| 1. | «Яхшы сүз-җан азыгы» |
| 2. | А.Алиш иҗаты |
| 3. | Хуш киләсең, ямьле көз! |
| 4. | Көз күчтәнәчләре |
| 5. | Мин яратам сине, Татарстан |
| 6. | Төсләр дөньясы |
| 7. | Кем эшләми , шул ашамый. |
| 8. | Җиләк-җимешләр |
| 9. | Минем гаиләм |
| 10. | Табын янында |
| 11. | Киемнәр дә  безне бизиләр |
| 12. | Салкын кыш. Кышкы уеннар. |
| 13. | Кунак булсаң-тыйнак бул |
| 14. | Киемнәр |
| 15. | Йорт җиһазлары |
| 16. | Муса Җәлил безнең күңелләрдә. |
| 17. | Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа |
| 18. | Без язны яратабыз |
| 19. | Безнең канатлы дусларыбыз |
| 20. | Габдулла Тукай иҗаты |
| 21. | Чисталыкта-матурлык |
| 22. | Җиңү алып килде май |
| 23. | Кунак көтәбез |
| 24. | Хәрәкәттә-бәрәкәт |
| 25. | Чәчәкле җәй. |
| 26. | Күңелле сабантуй |

## Мәктәпкә әзерлек

| | |
|---|---|
| 1. | Әйдәгез,танышабыз! |
| 2. | Тату гаилә |
| 3. | Абдулла Алиш иҗаты |
| 4. | Алтын көз |
| 5. | Көзге байлык |
| 6. | Көз күчтәнәчләре |
| 7. | Икмәк – яшәү терәге |
| 8. | Ашамлыклар |
| 9. | Савыт-саба |
| 10. | Өй җиһазлары |
| 11. | Милли киемнәр |
| 12. | Минем туган җирем |

| | |
|---|---|
| 13. | Башкалам - Казан |
| 14. | Кыргый хайваннар |
| 15. | Ишек алдында |
| 16. | Кыш килде |
| 17. | Кышкы уеннар |
| 18. | Кыш. Кышкы уеннар |
| 19. | Кышлаучы кошлар |
| 20. | Киемнәр |
| 21. | Муса Җәлил |
| 22. | И туган тел, и матур тел... |
| 23. | Безнең шәһәр |
| 24. | Ямьле яз |
| 25. | Әкияттә кунакта |
| 26. | Күчмә кошлар |
| 27. | Белем иленә сәяхәт |
| 28. | Мәктәп |
| 29. | Урман-безнең байлыгыбыз |
| 30. | Габдулла Тукай |
| 31. | Әкияттә кунакта |
| 32. | Җиңү бәйрәме |
| 33. | Без уйнарга яратабыз |
| 34. | Хуш бакчам, исәнме мәктәп |

## 1.6.Программа буенча белем бирү дәрәҗәсен билгеләү “Туган телдә сөйләшәбез” комплекты буенча (2вариант)

## Уртанчылар төркеме

| Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | | | Иллюстрациягә карап әсәрнең исемен әйтү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Ягымлы сүзләр | Боерыкны куллана белү | Үзең тур.сөйләү | Нинди?Нишли? соравына җавап бирү | Уенчыкларны санау (ничә?) | Аралаша белү (диалог) | |

## Зурлар төркеме

| Сүз байлыгы | | | Бәйләнешле сөйләм | | | Фольклор ( мәкаль, санамыш, табышмак, экиятләр) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Ягымлы сүзләр куллану | Сүзләрне гомуми-ләштерү | Капма-каршы сүзләр | Үзең турында сөйләү | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану | Аралаша белү (диалог) | |

**Мәктәпкә әзерлек төркеме**

<table>
<tr><td colspan="3">Сүз байлыгы</td><td colspan="3">Бәйләнешле сөйләм</td><td rowspan="2">Фольклор ( мәкаль, санамыш, табышмак, әкиятләр)</td></tr>
<tr><td>Ягымлы сүзләр куллану</td><td>Сүзләрне гомуми-ләштерү</td><td>Капма-каршы сүзләр</td><td>Үзең турында сөйләү</td><td>Рәсем буенча сөйләү</td><td>Аралаша белү (диалог)</td></tr>
</table>

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә | 2,7 дән 3 кә кадәр |
| Уртача дәрәҗә | 2 дән 2,6 га кадәр |
| Уртачадан түбән дәрәҗ | 1 дән 2 гә кадәр |

# 2.ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ

## 2.1. Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү (биш белем өлкәсендә)

**Социаль-коммуникатив үсеш.** Балаларның социаль характердагы беренче күзаллауларын булдыру һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү; хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру; үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә – тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Балаларның Татарстан Республикасы, анда яшәүче халыклар, аларның хезмәте һәм профессияләре, туган як табигате турында белемнәрен уен эшчәнлеге вакытында тирәнәйтү. Балаларда патриотизм хисләре; үзен туган шәһәре (авылы), республикасы, иленең гражданины итеп тану; шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимнга) хөрмәт белән карауны һәм горурлану хисе тәрбияләү. Иҗтимагый чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яшенә карамыйча, янәшәдә яшәүчеләргә (балаларга, өлкәннәргә) уңай мөнәсәбәт, түземлек (толерантлык); башка кешеләрнең хисләре, фикерләре, теләкләренә, карашларына хөрмәт тәрбияләү, үзенең башкалар фикере белән риза булмавын дәлилли яисә үз позициясен яклый белергә өйрәтү. Башка ил, этнос халыклары белән позитив аралашуның, хезмәттәшлек итүнең мәгънәсен аңлату. Якындагы социумда үз урыны, теге яки бу төркемдәге кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуы (балалар бакчасындагы төркем яисә бию түгәрәге әгъзасы, спорт мәктәбе укучысы, булачак гимназист һ. б.) турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә тарихына (карт бабай, бабай, карт әби, әби) карата кызыксыну тәрбияләү. Гаиләң белән горурлану хисләре, гаилә әгъзаларының уңышларына сөенү, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау күнекмәләре тәрбияләү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм мультипликацион фильмнары, әйләнә-тирәдәге тормыш турындагы күзаллауларын сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уеннарында иҗади куллануларына булышлык итү. Балаларның

сәхнәләштерү һәм кую өчен Идел буе халыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җырларын, биюләрен мөстәкыйль сайлап алуларын хуплау; куелачак спектакльгә кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләргә, үзара вазифаларны билгеләргә һәм рольләр бүлешергә булышу. Театральләшкән эшчәнлектә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, курчак, рәсемнәр һ. б. театрлар) куллану. Сәхнә сәнгатенә карата кызыксыну үстерү. Коллективта сүзле уеннар уйнарга омтылышларын хуплау. Идел буе халыклары уеннарын уйнау тәҗрибәсен баету.

**Танып-белү үсеше.** Балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү; Татарстан Республиканың төп символикасы, географик урыны, анда яшәүче халыкларның традицияләре, гореф–гадәтләре, йолалары белән таныштыру; туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү, туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү максатларын тормышка ашыра. Туган як тарихы, мәдәнияты, сынлы сәнгать, туган якның табигате белән таныштыру исәбенә балаларның күзаллауларын киңәйтү. Туган як табигате, климаты, кешеләренең тормышы белән таныштыруны дәвам итү. Үз шәһәренең (авылының) истәлекле урыннары, халык һөнәрләре, милли кухня, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасы белән таныштыру. Картада туган шәһәрен, республикасын, башкаланы, Татарстандагы эре шәһәрләрне (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән һ. б. ны) күрсәтә һәм атый белергә өйрәтү. Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар), аларның тарихы, культурасы, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүрешен чагыштырырга өйрәтү. Татар һәм рус халкының яши торган өе, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре үзенчәлекләренә игътибар итү. Туган шәһәрендә бара торган позитив үзгәрешләрне (балалар бакчалары, спорт комплекслары, театрлар һ. б. төзелү) күрә белергә өйрәтү. Казанның эре промышленность һәм сәүдә үзәге булуы, татар халкының элек-электән игенчелек, терлекчелек, күн эшкәртү, сәүдә белән шөгыльләнүе турында балаларга сөйләү. Туган шәһәренең, башка шәһәрләрнең символикасын өйрәнүне дәвам итү, үз халкының бер өлеше булуын аңлый белергә ярдәм итү. Милли һәм дөнья культураларының үткәненә һәм бүгенге сенә балаларны якынайту. Музыка һәм театр сәнгатенең күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштыру (композиторлар: С. Садыйкова, С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин һ. б., җырчылар: Ф. Шаляпин, И. Шакиров, Р. Ибраһимов һ. б., театр режиссёрлары: М. Сәлимҗанов, К. Тинчурин һ. б., В. Качалов, Г. Камал исемендәге театр актёрлары һ. б.). Аларның тормышларына һәм эшчәнлекләренә кызыксыну уяту. Күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм эшчәнлекләре белән таныштыру (Н. И. Лобачевский, К. Ф. Фукс, И. М. Симонов, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. Е. Арбузов һ. б.). Балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын канәгатьләндерү, Казан (Идел буе) федераль университеты укытучылары һәм аны тәмамлаучылар турында мәгълүмат бирү. Милләтебез каһарманнарының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында сөйләү (М. Җәлил, Г. Гафиятуллин, М. П. Девятаев, П. М. Гаврилов, Н. Г. Столяров һ. б.). Әти-әниләрне балаларга әби

һәм бабаларының сугышта алган бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучыларга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү (һәйкәлләр, обелискларга чәчәкләр кую һ. б.). Табигатьне саклау буенча балаларның белемнәрен тирәнәйтү. Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, табигатькә катнашуыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, табигатьнең ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, аны рациональ файдалану күнекмәләре формалаштыру. Үсемлек һәм җиләкләрне җыю кагыйдәләре белән таныштыру. Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүче тереклек ияләре, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлек (флора) һәм хайваннар (фауна) төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясында сирәк очрый торган төрләргә сакчыл караш кирәклеген балаларның аңнарына җиткерү. Татарстанның елга, күлләрендә яшәүче тереклек ияләре белән таныштыру. Кеше тормышында чишмә, елгаларның тоткан урыны, әһәмияте турында сөйләү. Республика сулыкларын чиста тотарга теләк уяту. Туган як табигатенең матурлыгына, андагы форма, ис, төс муллыгына игътибар итү. Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү.

**Сөйләм үсеше.** Әйләнә–тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һзм чараларын үзләштерү; балада китап укуда кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Балаларны матур әдәбият әсәрләре, халык әкиятләре, фольклоры белән таныштыру. Татар теленә карата тотрыклы кызыксыну үстерү. Мәгълүмати аралашу технологияләре, аудио- һәм видеоязмалар, уку-укыту методик комплектлары ярдәмендә предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне актив кулланышка кертү, гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре байлыгы булдыру. Балаларның сүз байлыгын арттыру. Төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен ныгыту. Үзе турында, бер кеше гамәлләрен сурәтләгән ситуатив картиналар сериясе буенча, сюжетлы рәсемнәр, үз күзәтүләреннән чыгып, зур булмаган (3–5 җөмләле) хикәяләр төзи белергә өйрәтү. Балаларның төрле эшчәнлек вакытында татар халык фольклор әсәрләрен, еш кулланыла торган сүзләр һәм әйтемнәрне файдаланууга омтылышларын хуплау. Татар телендә сөйләүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белүне формалаштыру, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышу, телне аз белүенә карамастан, аның белән әңгәмәгә кереп, аралашырга омтылышын хуплау. Балаларны татар телен киләчәктә (башлангыч мәктәптә) тагын да аңлабрак, төшенеп өйрәнергә әзерләү.

**Нәфис-нәфасәти үсеш.** Балаларда әйләнә–тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне; балаларның музыкальлекләрен, музыканы, матур әдәбият, фольклор әсәрләрен хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыра. Балаларны татар халкының сәнгате (музыка, бию, рәсем сәнгате, матур әдәбият әсәрләре), анда яшәүче атаклы кешеләр белән таныштырып, аларда әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү. Милләтебезнең

дини йолалары, халык авыз иҗаты, сынлы сәнгате һәм архитектурасы, музыка сәнгате белән таныштыру балаларда Туган илне ярату хисе тәрбияләргә булыша. Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү. Балалар белән «яшәү агачы» образын карау. Балаларның игътибарын композициянең үзенчәлегенә (симметриясез), шул ук вакытта төрле төсләр файдаланылган чәчәк бәйләменә юнәлдерү. Төрле материаллар кулланырга, реаль һәм экияти образларны (Идел буе халыклары экиятләрендәге геройларны да кертеп) сурәтләүнең төрле ысулларын берләштерергә мөмкинлекләр бирү. Республика тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемнәрдә чагылдыра белүләрен хуплау. Балаларның эшләрен бергәләп карау, нәрсә ясаганнары турында сөйли белергә өйрәтү. Балаларга эшләренең тематикасын киңәйтүгә булышлык итү. Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын натурадан карап әвәли һәм аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белергә өйрәтү. Ике-өч фигурадан торган скульптура төркемнәрен катлаулы булмаган сюжетларга («Сабантуйда», «Чәй эчкәндә», «Ат чабышлары» һ. б.га) берләштерү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре геройларын күзаллау юлы белән әвәли белү күнекмәләрен формалаштыру. Туган шәһәре (авылы) тормышындагы вакыйгаларны чагылдыручы сюжетларны мөстәкыйль сайлый белүләрен активлаштыру. Башка белем бирү өлкәләренең эчтәлеге белән ярак-лаштырып, балалар эшләренең тематикасын киңәйтү. Балаларны Г. Тукай әсәрләре һәм аның иҗатын чагылдыручы сәнгать төрләре (Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бәшировның «Су анасы» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» симфониясе, Б. Урманче, И. Казаков, Б. Әлменов, Ф. Әминов һ. б. ның сынлы һәм рәсем сәнгатьләре әсәрләре) белән таныштыруны дәвам итү. Сәнгатькә карата уңай караш формалаштыру. «Казан» милли-мәдәни үзәгенең милли-мәдәният музеенда булу, анда борынгыдан сакланып калган өй кирәк-яраклары: көмеш поднослар, савыт-саба, бизәк төшерелгән бакыр кувшиннар, комганнар, йорт хайваннары фигуралары формасындагы бронза йозаклар; җәмәгать биналарының интерьерларын һәм экстерьерларын бизәүче декоратив композицияләр белән таныштыру. Борынгы бизәнү әйберләрен: йөзекләр, алкалар, беләзекләр, чулпылар, яка чылбырлары, хәситәләр һ. б.ны карау. Хәзерге заман рәссам-ювелирларның (И. Фазылҗанов, С. В. Ковалевская, В. О. Ковалевский һ. б.ның) иҗатлары белән таныштыру. Балаларның игътибарын бизәнү әйберләренең милли үзенчәлекләренә юнәлдерү. Татар халкының үзенчәлекле сәнгати һөнәре булган укабелән чигү турында сөйләү. Чигелгән түбәтәйләр, хатынкызның бәрхет аяк киеме, күкрәкчәләр, калфаклар һ. б.ны карау. Бигрәк тә популяр булган композицияләргә – «алтын каурый», чәчәк бәйләме, кошлар, бодай башагы, йолдызлар һәм ярымай мотивларына һ. б.га игътибар итү. Туган шәһәр (авыл) архитектурасы – мәчет һәм храм архитектуралары (Кол Шәриф мәчете, Раифадагы Богородицкий ир-атлар монастыре) белән таныштыру эшен дәвам итү. Балаларны татар халкының музыка культурасына якынайту. Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлау. Татарстан

Республикасы, Россия Федерациясенең Дәүләт гимннары белән таныштыру. Горурлык хисләре тәрбияләү.

**Физик үсеш.** Балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру; физик культура эшчәнлегенә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Татар халык хәрәкәтле уеннарын, физминуткалар кулланып балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү, татар халык бәйрәмнәре, халык уеннары аша балаларның физик үсешен камилләштерү. Чәй янына бирелә торган милли камыр ризыклары: гөбәдия (дөге, йөзем һәм йомырка белән), кабартма, бавырсак, талкыш-кәләвә, чәкчәк, кош теле белән таныштыру. Балаларга республикадан читтә дә танылган дәвалану-ял итү урыннары һәм санаторийлар («Васильево», «Сосновый бор» («Нарат урманы»), «Крутушка», «Бакирово», «Санта» һ. б.) белән танышу мөмкинлеге бирү. Хәрәкәтле халык уеннарын үзгәртеп төрләндерү күнекмәләре бирү. Милли уен-ярышларда («Таяк тартыш», «Аркан тартыш», «Капчык белән сугыш» һ. б.да) катнашасы килү теләге уяту. Кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллау формалаштыру. Милли спорт төре – көрәш белән таныштыру. Спорт өлкәсендәге билгеле уңыш-казанышлар белән таныштыру. Идел буе халыкларының төрле эчтәлекле уеннарын мөстәкыйль эшчәнлек вакытларында файдалана белү күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтле уеннарда балаларда көч, җитезлек, кыюлык, тәвәккәллек, түземлек кебек сыйфатлар тәрбияләү. Уен нәтиҗәсен гадел бәяли белүләрен хуплау. Халык уеннары белән кызыксынуларын үстерү

## 2.2. Эш төрләре һәм формалары.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү
(эти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар;.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 2.3. Ана теленнән (икенче вариант) комплекслы- тематик планнар.

## Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1. Без балалар бакчасында | Танышу<br>Без балалар бакчасында | 1<br>1 |
| 2. Мин - дөньяның бер кешесе | Әти, әни һәм мин<br>“Гаилә” рәсемен карау.<br>Г. Тукай “Безнең гаилә”шигырен уку.<br>Г. Тукай “Безнең гаилә”шигырен ятлау.<br>Мин һәм кешеләр | 1<br>1<br>1<br>1<br>2 |
| 3. Ю | Б.Рәхмәт “Су” шигырен уку.<br>Б.Рәхмәт “Су” шигырен ятлау | 1<br>1 |
| 4. Көз | Көз килде<br>“Көз”рәсемен карау | 1<br>1 |
| 5. Куян күчтәнәчләре | Куян күчтәнәчләре | 2 |
| 6. Көз күчтәнәчләре | Җимешләр.<br>Р.Батулла “Аю Әппәс” әкиятен сөйләү | 1<br>1 |
| 7. Табын янында. | Ашамлыклар<br>Әбине сыйла<br>Сыйла<br>Без кибеткә барабыз, ашамлыклар алабыз<br>Аш бүлмәсе | 2<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8. Татар халык ашлары. | Татар халык ашлары. | 2 |
| 9. Безнең уенчыклар | Безнең уенчыклар<br>Әйдәгез уйныйбыз<br>Безнең уенчыклар<br>Уенчыклар белән уйныйбыз<br>Уенчыклар кибете<br>Безнең уенчыклар<br>Без уйнарга яратабыз<br>Уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. Кыш | Җәнлекләр кышка әзерләнә<br>Җәнлекләр кышкы урманда<br>А.Алиш”Куян кызы”<br>Кыргый хайваннар<br>Хәйдәрнең “Керпе туны”әкиятен уку<br>Ә.Бариның “Кыш”шигырен уку. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 11. Халык җәүһәрләре | Киемнәр | 2 |
| 12. Ватанны саклаучылар. | Безнең Армия<br>Хәрби һөнәрләр<br>Очучылар<br>Без солдатлар<br>К. Булатованың “Солдатлар” шигырен уку.<br>Иң яхшы әти. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 13. 8 март | Әнием турында сөйлим<br>З.Туфайлованың “Әни сүзе” шигырен ятлау. | 1<br>1 |
| 14. Яз | Кар Бабай язны эзли<br>Яз бүләкләре<br>Нур Гайсин “Яз килә”шигырен уку<br>“Без язны яратабыз” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 15. Күчмә кошлар | Күчмә кошлар<br>Бергәләп өйрәник<br>Х.Вахитның “Уңган сыерчык”шигырен уку.<br>Б. Рәхмәтнең “Яз ”шигырен ятлау. | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 16. Савыт-саба | Савыт-саба<br>Бергәләп уйныйбыз<br>Кунак чакырабаз<br>Күңелле ял итәбез | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 17. Апрель җитсә, исемеңне җырына куша тургай | Габдулла Тукай<br>Без татарча сөйләшәбез<br>Г. Тукай “Кызыклы шәкерт” шигырен уку<br>Г.Тукай” Гали белән кәҗә” шигырен ялау | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 18. Йорт хайваннары | Йорт хайваннары<br>Бу өйдә кем яши | 1<br>1 |
| 19. Минем дусларым | “Торна белән Төлке” әкиятен уку.<br>Без татарча сөйләшәбез<br>Җ.Тәрҗемановның ”Кикрикүк”шигырен уку<br>А.Алиш “Чукмар белән Тукмар” әкияте | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 20. Сабантуй бәйрәме | Сабантуйга әзерләнәбез<br>Күңелле Сабантуй | 1<br>1 |
| | | 72 сәгать |

## Зурлар төркеме (5-6яшь)

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1. «Яхшы сүз-җан азыгы» | Танышу<br>Ягымлы сүзләр<br>Сыйла(катнаш эшчәнлек) | 1<br>1<br>1 |
| 2. А.Алиш иҗаты | А.Алиш- балалар язучысы.<br>А.Алиш “Каз белән аккош” | 1<br>1 |
| | «Чукмар белән Тукмар» (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 3. Хуш киләсең, ямьле көз! | Җәйләр үтте, көзләр җитте.<br>Көзге табигать | 1<br>1 |
| | “Шалкан” (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 4. Көз күчтәнәчләре | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт<br>Сыйлыйбыз | 1<br>1 |
| | “Баллы кишер” (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| | Түтәлләрдә үсте яшелчә<br>Яшелчәләр кибете<br>Бар матур бакча | 1<br>1 |
| 5. Мин яратам сине, Татарстан | Мин яратам сине, Татарстан<br>Туган җирем- Татарстан | 1<br>1 |
| | “Уйный-уйный эшлибез” | 1 |
| | Гүзәл туган ягыбыз | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Туган ил кайдан башлана? | 1 |
| | Мультфильм “Акбарс” | 1 |
| 6. Төсләр дөньясы | Төсләр<br>Төсләр дөньясы | 1<br>1 |
| | “Юл маҗаралары”. | 1 |
| 7. Кем эшләми , шул ашамый. | Яшелчә салаты<br>Яшелчәләр юабыз. | 1<br>1 |
| | “Кем эшләми, шул ашамый” | 1 |
| 8. Җиләк-җимешләр | Җимешләр<br>Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>Җиләк-җимешләр | 1<br>1<br>1 |
| 9. Минем гаиләм | Безнең гаилә<br>Әби , бабайларны хөрмәтлик. | 1<br>1 |
| | “Аш бүлмәсе” | 1 |
| 10. Табын янында | Савыт-саба кибетенә сәяхәт.<br>Савыт-саба.<br>Бергәләп өйрәнәбез.<br>Курчак Алиягә булыш<br>Чәй табыны | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | “Өч аю” . | 1 |
| 11. Киемнәр дә безне бизиләр | Кием кешене бизи<br>Кием - салым кибетенә сәяхәт | 1<br>1 |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 |
| 12. Салкын кыш. Кышкы уеннар. | Салкын кыш<br>Кышкы уеннар | 1<br>1 |
| | “ Хат ташучы Кар бабай.” | 1 |
| | Без суыктан курыкмыйбыз.<br>Кыш<br>Кабатлау Савыт –саба кибетендә | 1<br>1<br>1 |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 |
| | Кышкы уеннар<br>Ел фасыллары | 1<br>1 |
| | Куян кызы | 1 |
| 13. Кунак булсаң- тыйнак бул | Без ашыйбыз<br>Мин кунак яратам<br>Бергәләп өйрәнәбез | 1<br>1<br>1 |
| 14. Киемнәр | Киенергә ярдәм ит<br>Милли киемнәр. | 1<br>1 |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 |
| | Киемнәр дә безне бизиләр.<br>Киемнәр дөняьсы | 1<br>1 |
| | ”Ни өчен киемнәр югалган” | 1 |
| 15. Йорт җиһазлары | Матур әдәбият белән таныштыру өстәл театры “Өч аю”.<br>Өй җиһазлары кибете. | 1<br>1 |
| | “Маша һәм өч аю” | 1 |
| 16. Муса Җәлил безнең күңелләрдә. | Муса Җәлил безнең күңелләрдә.<br>“Батыр лыкта-матурлык”. | 1<br>1 |
| | “Шаян уенчыклар”. | 1 |
| 17. Кояш гомере телим мин, әнием, | Без әни белән кибеткә бардык<br>Әниләр бәйрәме | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| сиңа | | |
| | “Өч кыз” | 1 |
| | Әни кирәк<br>Әниемнең тәмле ашлары | 1<br>1 |
| | Бар, юк | 1 |
| 18. Без язны яратабыз | Яз килә.<br>Яз килә, яз! | 1<br>1 |
| | Алтын ай кибете | 1 |
| | Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>Нәүрүз – яз бәйрәме<br>Туган көн | 1<br>1<br>1 |
| 19. Безнең канатлы дусларыбыз | Күчмә кошлар<br>Кошлар | 1<br>1 |
| | Кем нәрсә ярата | 1 |
| 20. Габдулла Тукай иҗаты | Габдулла Тукай<br>Г. Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырен уку. | 1<br>1 |
| | Тукай әсәрләреннән төзелгән мультфильмнардан өзекләр карау. | 1 |
| | Г. Тукай “Безнең гаилә”<br>“Гаилә” рәсемен карау | 1<br>1 |
| | Г. Тукай “Бала белән күбәләк” | 1 |
| 21. Чисталыкта-матурлык | Саулык-зур байлык<br>Шигырь уку: Ә.Ерикәй “Чисталык сөябез” | 1<br>1 |
| | “Чисталыкта-матурлык” | 1 |
| 22. Җиңү алып килде май | Сугыш ветераннары белән очрашу | 1 |
| 23. Кунак көтәбез | “Винни-пух кунакка бара”. | 1 |
| | “Чебурашка” | 1 |
| 24. Хәрәкәттә-бәрәкәт | Минем яраткан спорт төре.<br>Шигырь уку: В Хәйруллина “Туплар” | 1<br>1 |
| | Арыслан баласы һәм ташбака ничек җыр җырлаган” | 1 |
| 25. Чәчәкле җәй. | Чәчәкләр – тормыш яме<br>Чәчәкле җәй. | 1<br>1 |
| | Сабантуй бәйрәме | 1 |
| 26. Күңелле сабантуй | Күңелле Сабантуй уеннары<br>Сабан туена әзерлек<br>Сабан туена әзерлек | 1<br>1<br>1 |
| | | **102** |

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)

| **Проект темалары** | **Эшчәнлек төрләре** | **Эшчәнлек саны** |
|---|---|---|
| 1. Әйдәгез, танышабыз! | Әйдәгез, танышабыз<br>Тәмле сүз – җан азыгы | 1<br>1 |
| | “Мияу адашкан” | 1 |
| 2. Тату гаилә | Минем өем<br>Тату гаилә | 1<br>1 |
| | “Аю баласы дөнья белән таныша” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 3. Абдулла Алиш иҗаты | А. Алиш иҗаты белән танышу.<br>А.Алиш “Сертотмас үрдәк” әкияте | 1<br>1 |
| | «Батыр Мияу белән куркак Куянкай» | 1 |
| 4. Алтын көз | Алтын көз<br>Көз җитте | 1<br>1 |
| | “Шалкан” | 1 |
| 5. Көзге байлык | Яшелчәләр | 2 |
| | «Кем эшләми, шул ашамый.” | 1 |
| 6. Көз күчтәнәчләре | Җиләк-җимешләр<br>Көз күчтәнәчләре | 1<br>1 |
| | “Без сыйланабыз” | 1 |
| 7. Икмәк – яшәү терәге | “Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә”<br>Кунак чакырдык | 1<br>1 |
| | “Юмарт аю” | 1 |
| 8. Ашамлыклар | Ашамлыклар<br>Кунак көтәбез | 1<br>1 |
| | “Кафега барабыз” | 1 |
| 9. Савыт-саба | Савыт-саба | 2 |
| | “Тәмле” кафесы ачабыз | 1 |
| 10. Өй җиһазлары | Минем өем, өй җиһазлары | 1 |
| | “Тәмле” кафесында | 1 |
| 11. Милли киемнәр | Әбиемнең серле сандыгы<br>Кием кешене бизи | 1<br>1 |
| | “Күңелле уеннар” | 1 |
| 12. Минем туган җирем | Татарстан буйлап сәяхәт<br>Спорт бәйрәменә барабыз | 1<br>1 |
| | “Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” | 1 |
| 13. Башкалам - Казан | Башкалам - Казан<br>“Туган илем – туган өем” | 1<br>1 |
| | Әниләр бәйрәменә барабыз | 1 |
| 14. Кыргый хайваннар | Кыргый хайваннар | 2 |
| | “Циркта” | 1 |
| 15. Ишек алдында | Йорт кошлары<br>Йорт хайваннары | 1<br>1 |
| | “Төлке һәм каз”мультфильмы | 1 |
| 16. Кыш килде | Кыш килде<br>Кыш | 1<br>1 |
| | “Безнең дуслар” | 1 |
| 17. Кышкы уеннар | Кышкы уеннар<br>Яңа ел бәйрәме | 1<br>1 |
| | “Кар малай” мультфильмы | 1 |
| 18. Кыш. Кышкы уеннар | Кыш. Кышкы уеннар | 2 |
| | “Шаян кошлар” | 1 |
| 19. Кышлаучы кошлар | Кышлаучы кошлар<br>Кошлар кафесы<br>“Әйдә, бие!” | 1<br>1<br>1 |
| | Кышлаучы кошлар<br>Кошларга ярдәм итик! | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | “Урманда зур концерт” | 1 |
| 20. Киемнәр | Киемнәр<br>Кышкы киемнәр | 1<br>1 |
| | “Акбай туган көнгә барырга әзерләнә” | 1 |
| 21. Муса Җәлил | Муса Җәлил | 2 |
| | “Мияуның туган көне” | 1 |
| 22. И туган тел, и матур тел... | Бөтендөнья телләр көне<br>И туган тел, и матур тел... | 1<br>1 |
| | “Урман китапханәсендә” | 1 |
| 23. Безнең шәһәр | Безнең шәһәр | 2 |
| | “Уйный-уйный укыйбыз” | 1 |
| 24. Ямьле яз | Ямьле яз | 2 |
| | «Урман мәктәбендә» | 1 |
| 25. Әкияттә кунакта | Әкияттә кунакта<br>“Хуш киләсең, Нәүрүз!” | 1<br>1 |
| | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү | 1 |
| 26. Күчмә кошлар | Күчмә кошлар | 2 |
| | “Кем нәрсә ярата?” | 1 |
| 27. Белем иленә сәяхәт | Белем иленә сәяхәт<br>Серле чәчәк<br>Уку бүлмәсе | 2<br>1<br>1 |
| | “Уйный-уйный укыйбыз” | 1 |
| 28. Мәктәп | Без мәктәпкә барабыз | 2 |
| | “Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар” | 1 |
| | Уку бүлмәсе<br>Белем иленә сәяхәт<br>“Юл маҗаралары” | 1<br>1<br>1 |
| 29. Урман-безнең байлыгыбыз | Урманда<br>Нәрсә ул “Кызыл китап? | 1<br>1 |
| | Габдулла Тукай | 1 |
| 30. Габдулла Тукай | Г. Тукай әкиятләренә сәяхәт<br>Без - Тукай оныклары | 1<br>1 |
| | Г. Тукай “Шүрәле” | 1 |
| 31. Әкияттә кунакта | «Эш беткәч, уйнарга ярый»<br>Могҗизалар кыры<br>Сюжетлы-рольле уеннар | 1<br>1<br>1 |
| 32. Җиңү бәйрәме | Алар безгә җиңү бүләк итте<br>Җиңү бәйрәме<br>“Алтын бөртекләр” | 1<br>1<br>1 |
| 33.Без уйнарга яратабыз | Белем иленә сәяхәт<br>Без уйнарга яратабыз<br>Казанга спорт бәйрәменә барабыз<br>«Агачлар да авырый»<br>Без уйнарга яратабыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 34. Хуш бакчам, исәнме мәктәп | Кабатлау.<br>«Хуш бакчам, исәнме мәктәп» | 1<br>1 |
| | | **108 сәгать** |

## 2.4. Балалар белән эш

| № | Уткәреләсе чаралар | Уткәрувакыты |
|---|---|---|
| 1. | Балаларны, Манюрова Г. Х. нын «Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел» методик пособиясен кулланып, ана теленә өйрәтү. | Ел дәвамында. |
| 2. | Уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәрдә программа материалын үзләштерү буенча диагностика уздыру. | Октябрь апрель |
| 3. | Үткәрелгән мониторинг нәтиҗәләре буенча программа материалын авыр үзләштерүче балалар белән индивидуаль эш алып бару. | Циклограмма буенча. |
| 4. | Сәләтле балалар белән эш алып бару:<br>-махсус әдәбият белән танышу;<br>-төрле конкурсларга әзерләнү һәм катнашу;<br>- бәйрәмнәргә, иртәләргә шигырьләр, җырлар өйрәнү;<br>- әсәрләрне сәхнәләштерү. | Циклограмма буенча. |
| 6. | Балалар белән ачык шөгыль курсәтү. | Квартал саен. |
| 7. | Балаларны шәһәр, республика күләмендә үткәреләчәк конкурсларга эзерлэу. | Ел дәвамында |

## 2.5. Ата- аналар белән эш

| № | Уткәреләсе чаралар | Уткәру вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Кечкенәләр төркемендә яңа килгән балаларның ата-аналары белән анкета үткәрү | Октябрь |
| 2. | Ата-аналар җыелышында чыгыш ясау “Дәүләт телләрен өйрәнү нәтиҗәләре” | Май |
| 3. | Балалар бакчасының сайтында укыту-методик комплекты турындагы мәгълүмәтләрны яңартып тору | Кварталга бер |
| 4. | Төркемнәрдә ата-аналар почмакларында ана теле шөгыльләре буенча мәгълүмәтләрны яңартып тору. | Атна саен |
| 5. | Ата –аналар белән шәхси консультацияләр һәм әңгәмәләр үткәрү | Циклограмма буенча |
| 6. | Милли бәйрәм һәм күңел ачу чаралары, конкурслар, күргәзмәләргә әзерләнүгә һәм үткәрүгә ата – аналарны җәлеп итү:<br>- «Милли атналык»;<br>- «Татар мәдәнияте атналыгы»; | Ноябрь Февраль |

| | | |
|---|---|---|
| | - Габдулла Тукай иҗатына багышланган кичә<br>- Нәүрүз<br>- Сабантуй | Апрель<br>Март<br>Июнь |
| 7. | Ачык ишекләр көне үткәрү: «Милли атналык» кысасында; | Ноябрь |
| 8. | Ачык ишекләр көне үткәрү: «Татар мәдәнияте атналыгы» кысасында; | Февраль |
| 9. | Ата-аналар өчен консультациялэр булдыру:<br>«Ике дәүләт теленә өйрәтү буенча заманча эффектив белем технологиясе буларак УМК материалларын куллану »;<br>«Матур әдәбият әсәрләре аша балаларда әхлак хисләре тәрбияләү»;<br>«Балаларны матурлык аша тәрбияләүдә халык авыз иҗатының роле». | 1 квартал<br><br>2 квартал<br><br>3 квартал |

## 2.6.Педагоглар белән эш

| № | Уткәреләсе чаралар | Уткәрү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Уку елына УМК буенча эш планы белән, ана теленнэн перспектив планнар белән таныштыру. | Август. |
| 2. | Тәрбиячеләрне диагностика нәтиҗәләре белән таныштыру. | Октябрь,<br>май |
| 3. | Төркеменәрдә сәләтле балаларны ачыклау-тәрбиячеләр белән киңәшмә. | Сентябрь. |
| 4. | Төркемнәрдә балаларнын эшчәнлекне ничек үзләштерүе буенча тәрбиячеләр белән индивидуаль эш алып бару буенча әңгәмә. | Циклограмма буенча. |
| 5. | Милли атналыкларында балалар бакчасының еллык планына нигезләнеп үткәреләсе чараларына эшкәртмәләр әзерләү һәм үткәрү. | Ноябрь, февраль |
| 5. | УМК почмакларын тулыландыру буенча эш алып бару:<br>- дидактик уеннар,<br>-лэпбуклар,<br>-ковробуклар | <br><br>1 квартал<br>2 квартал<br>3 квартал |
| 6. | Консультацияләр:<br>- «Балаларны дәүләт телләренә өйрәтүдә УМКаны куллану».;<br>- «Укыту-методик комплектын кулланып балаларны татар теленә өйрәтүдә дидактик уеннарның әһәмияте»;<br>-«Баланың сөйләм телен ничек үстерергә?» | Кварталга бер |

## 2.7. Җәмгыять оешмалары  белән бәйләнеш

| № | Уткәреләсе чаралар | Уткәру вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Мәктәп һәм бакча балалары белән уртак бәйрәмнәр үткәрү | Кварталга бер |
| 2. | Ата- аналар җыелышларына мәктәп укытучыларын чакыру | Кварталга бер |
| 3. | Үзара эшчәнлек һәм дәресләр карау. | Октябрь, апрель |
| 4. | Шәһәр китапханәләре белән тыгыз элемтәдә эшләү: китапханә оештырган төрле бәйгеләрдә катнашу, китапханәләргә экскурсия оештыру | Ел дэвамында |
| 5. | Дәүләт советы, территориаль җәмәгать үзидарә органнары белән тыгыз элемтәдә эшләү | Ел дэвамында |

## 2.8. Педагогик процессны тулыландыру.

| № | Уткәреләсе чаралар | Уткәрувакыты |
|---|---|---|
| 1. | “Ана теле”  буенча курсәтмә материалны тулыландыру:<br>- уртанчылар<br>- зурлар<br>- мәктәпкә әзерлек төркеме | 1 квартал<br>2 квартал<br>3 квартал |
| 2. | “ Ана теле” буенча:<br>- дидактик уеннар;<br>- лэпбуклар;<br>- ковробуклар. | 1 квартал<br>2 квартал<br>3 квартал |

## 2.9. Уз белеменне устеру, квалификация кутэру буенча эш

| № | Уткәреләсе чаралар | Уткәру вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Балалар бакчалары белән  тәҗрибә уртаклашу. | план буенча |
| 2. | Оештырылган бәйгеләрдә катнашу | Ел дэвамында |
| 3. | Педагогик сәгатьтә консультация белән чыгыш ясау. “Эшлекле уенга материаллар эзерләү” | Октябрь |
| 4 | Педагогик сәгатьтә консультация белән чыгыш ясау. “Балалар бакчасында балаларның сөйләм телен үстерү, икетеллелек үзенчәлекләре” | Декабрь |

## 3.ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ

### 3.1. Материаль - техник яктан тәэмин ителеш

- ноутбук;
- проектор;
- экран;
- интерактив такта;
- дидактик уеннар;
- күрсәтмә рәсемнәр;
- таратма рәсемнәр;
- методик кулланмалар;
- электрон уеннар;
- аудио һәм видео дисклар.

### 3.2. Программалар белән һәм методик яктан тәэмин ителеш

- Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. Казань, 2011
- Закирова К.В. На поляне детства: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. Казань, 2011
-Зарипова З.М “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, “Хәтер”, 2011
-Зарипова З.М. “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, “Хәтер”, 2012
-Зарипова З.М. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, “Татарстан китап нәшрияты”, 2012
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез”2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, 2012
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез” 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, 2013
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез” 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, 2015
-Зарипова З.М. “Туган телдә сөйләшәбез”5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, 2012
- Манюрова Г.Х., Зарипова З.М. “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел”. Казань: ИРО РТ, 2016.-1 часть.
Манюрова Г.Х., Зарипова З.М. “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел”. Казань: ИРО РТ, 2017.-2 часть.
-Шаехова Р.К. “Радость познания – Сөенеч” Региональная программа дошкольного образования

## 3.3. Тавышлы күрсәтмәлелек

-Зарипова З.М. “Минем өем” проеты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
-Зарипова З.М. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
-Зарипова З.М. “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”, проекты буенча 6-7 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
-Зарипова З.М. “Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012
-Зарипова З.М. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен аудиоязмалар
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез” 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен аудиоязмалар
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез” 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен аудиоязмалар
- “Танцы народов Поволжья” аудиодиск
-Аудио-китап “Татар әкиятләре” мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен
-З.Г.Ибраһимова. Шома бас: мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар бию хәрәкәтләре өйрәтү буенча аудио-кушымталы методик кулланма
-Татар телендә мультфильмнар. № 1-5
-Луиза Батыр-Булгари. Музыкальные сказки на татарском языке. Болтливая утка.
-Луиза Батыр-Булгари. Африка хикмәтләре.
-Луиза Батыр-Булгари. Бииләр итек-читекләр.

## 3.4.Күрсәтмә, таратма материал

-“Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен демонстрацион һәм таратма материал.
-“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен демонстрацион һәм таратма материал.
-“Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча6-7 яшьлек балалар өчен демонстрацион һәм таратма материал.
-Хәзрәтова Ф.В.“Туган телдә сөйләшәбез” 2-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен демонстрацион материал.
-Зарипова З.М.“Туган телдә сөйләшәбез”5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен демонстрацион материал.

### 3.5. Норматив документлар

1. Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании»;
2. Закон Республики Татарстан от 8 июля 1992года №1560 – XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» (с учетом новой редакции Закона Республики Татарстан от 12 июня 2014 г. № 53 – 3 РТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан»);
3. Закон Республики Татарстан от 17 июня 2015 г. N 40-ЗРТ "Об утверждении Стратегии социально-экономического развития Республики Татарстан до 2030 года";
4. Постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 30.12.2010 года №1174 «Об утверждении Стратегии развития образования в Республике Татарстан на 2010-2015 годы «Килэчэк» - «Будущее»;
5. Постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 17.06.2015 № 443«Об утверждении Стратегии развития воспитания обучающихся в Республике Татарстан на 2015-2025 годы»;
6. Государственную программу «Реализация государственной национальной политики в Республике Татарстан на 2014-2020 годы»;
7. Государственную программу «Развитие образования и науки Республики Татарстан на 2014-2020 годы».
8. Государственную программу «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014-2020 годы».

### Файдаланылган әдәбият

-Борһанова Р. А., Юсупов Ф. Ф. Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. – Казан: РИЦ «Школа», 2004.
- Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә Туганнан алып мәктәпкәчә. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы. — Казан: Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшр., 2016.
-З.М.Зарипова, Р.Г.Кыйдрәчева Л.Ә.Шәрипова. Рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. Казан , 2011.
-З.М.Зарипова, А.И.Камалова, И.И.Хәмитова "Туган телем – бөек анам теле." Яр Чаллы , 2004.
- Г.Х. Манюрова, З.М. Зарипова "Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел". Казань:
ИРО РТ, 2016.
- Р.К. Шаехова "Сөенеч – Радость познания: региональная образовательная программа дошкольного образования". Казань, 2016.